# Роза Хәбибуллина

Презентацияне төзүче:
Мөслим районы Түбән Табын төп гомуми мәктәбе
8 нче сыйныф укучысы Бухарин Айзат Әлфис улы
Укытучы: Шакирова Әлфия Мөнир кызы



Тирә-ягыма карыйм да дөньяның гүзәллегенә исем китә.Нурлы кояш астында шаулап үскән урманнар, шул урман аланнарында үскән көмеш сабаклы умырзаялар, тургай җырына күмелгән зәңгәр җитен басулары, тауларыбыздан челтерәп аккан саф сулы чишмәләр, яңа пешеп чыккан ипинең хуш исләре-барысы да безнең бәхет өчен яратылгандыр, шушы оҗмахта һәркемнең үз өлеше бардыр.



“Барлык хезмәти гомерен балаларга багышлаган Роза Шакир кызы әдәбиятка ашыкмыйча килде. Рус әдәбиятын бик яхшы белгән абруйлы педагог татар әдәбиятына да битараф булмаган.

...Ул татар әдәбиятын даими укып барган, дәверебезнең иң яхшы әсәсрләрен җаны аша үткәргән, күңел байлыгы туплаган. Аннан инде үзенең дә кешеләргә , бигрәк тә яшь буынга әйтер сүзе барлыгын тоеп, кулына каләм алган.” (Факил Сафин)







Роза Хәбибуллина 2013 нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. Саҗидә Сөләйманова исемендәге кызыксындыру бүләге иясе(2014)



Әмәкәй (1934). 1959 нчы елда Алабуга пединститутының филология бүлеген тәмамлый. 1959 — 1990 нчы елларда Мөслим урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 90 нчы елларда аның дистәләгән очерклары, хикәяләре, новеллалары матбугатта күренә башлый.

# Аның әсәрләрен укып, беркем дә битараф кала алмый


Район медиклары исәбендә күпме коткарылган гомерләр, күпме сәламәт туган балалар һәм бәхетле аналар, күпме кире кайтарылган сәламәтлек,өмет...




...Тәрәз артындагы тоташ аклык аңа бәхетләр вәгъдә итә сыман. Бары тик кошлар карын койган миләшләрнең кызыл тәлгәшләре генә әлеге ак муллыкны сискәндереп куйгандай итә



**Калморза – автобиографик новелла. Ул сабый чак, балачак турында. И газиз дә, кадерле дә соң! Гомернең гел истә, күңел турында сакланган чагы! Ул онытылмый, гомернең иң азагына кадәр синең белән ияреп бара…**







**Ул авыл хәзер Татарстан картасында юк инде... Калморза халкы рәхәт тормыш эзләп авылларын ташлап качмаган – Кама сусаклагычында су күтәрелгәч, су басачак дип, Иске Александровка авылына күченгәннәр.**






# Авторның һәр әсәре кешеләр тормышыннан алып язылган

Әсәрдә  кешеләрнең намус, вөҗдан, игелеклелек, фидакярлек, мәхәббәт, тугрылык кебек сыйфатлары турында бәян ителә




Китапта язучының шагыйрь  тормышын һәм иҗатын чагылдырган “Гомер сандыгы” дигән әдәби-документаль бәяны урын алган



# Роза Хәбибуллинаның иҗатын язучы каләмдәшләре югары бәяли







# Өлкән яшьтә булуына карамастан, Роза Хәбибуллина бүген дә актив иҗат итә.









**Игътибарыгыз**

**өчен**

**рәхмәт**